КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 33

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 июнь, 459 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 14 нче; 2021 ел, 26 апрель, 285 нче; 2022 ел, 15 август, 835 нче; 2023 ел, 5 май, 572 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан С.Р.Андреевны, Г.Р.Сәгыйтованы чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абзалов Азат Искәндәр улын | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча) |
| Мөҗипов Рәмис Гаптрәис улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасарын |

Рафис Тимерхан улы Борһановның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

Марат Мансур улы Бариевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Спорт советы» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «Татарстан Республикасы Спорт гимнастикасы федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча)»;

Раушан Булат улы Зариповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм идарәсе башлыгы»;

Альберт Шамил улы Баһаветдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Спорт ветераннары советы рәисе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин